**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ЛАШМАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ЛАШМАНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

423110, Лашман авылы, Советлар урамы,55Айорт
Телефон (84396)2-92-35
Факс (84396) 2-92-35
Email: Lash.Cmn2@tatar.ru

423110. село Лашманка,
ул.Советская д55А
Телефон (84396) 2-92-35
Факс (84396) 2-92-35
Email: Lash.Cmn2@tatar.ru

**№ 51** **18.05.2022 ел**

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Лашман авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Муниципаль районның җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләрен кабул итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2006 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2022 елның 31 мартындагы 103 номерлы «Муниципаль районның авыл җирлекләренә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен тапшыру турында» карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлегенә җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Лашман авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен эшләү, үзгәрешләр кертү өлешендә вәкаләтләрне тапшыру турында тәкъдимен кабул итәргә.
2. Лашман авыл җирлеге башлыгына муниципаль район башлыгы белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Лашман авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Чирмешән муниципаль районы
Лашман авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе: Р.Г.Фәттахов